КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 31 октябрь г.Казань № 1375

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтүгә республика конкурсы турында» 2015 ел, 18 февраль, 99 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 3 ноябрь, 814 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның беренче абзацында «бюджет» сүзен «казна» сүзенә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтүгә республика конкурсы турындагы нигезләмәдә:

1.2 пунктта «дәүләт учреждениесе» сүзләрен «дәүләт казна учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Конкурс комиссиясе составына Иҗтимагый палата аппараты, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның $31^1$ статьясындагы 1 һәм 2 пунктларында каралган эшчәнлек юнәлешләре буенча дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру өчен җаваплы башка республика башкарма хакимият органнары, социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты һәм Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе (килешү буенча).»;

3.6 пунктның 6 пунктчасында «җирле үзидарә органнары» сүзләре алдына «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең» сүзләрен өстәргә;

5.11 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарыннан» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнарыннан» сүзләренә алмаштырырга, «җирле үзидарә органнары» сүзләре алдына «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең» сүзләрен өстәргә;

әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында:

«Җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)»;

«Ф.И.О.» аббревиатурасын «Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтүгә республика конкурсын үткәрү буенча конкурс комиссиясе составын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы вәкилләренең гамәлгә куючысы Татарстан Республикасы булган автоном коммерциягә карамаган оешмаларның идарә органнарында катнашу тәртибен раслау турында» 2015 ел, 26 июнь, 466 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 12 ноябрь, 1034 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы вәкилләренең гамәлгә куючысы Татарстан Республикасы булган автоном коммерциягә карамаган оешмаларның идарә органнарында катнашу тәртибендә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы вәкилләре тиешле өлкәдә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы республика башкарма хакимият органы (алга таба – республика башкарма хакимият органы) тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнә.»;

4 пунктның өченче абзацында татар текстында «башкарма хакимият органы белән төзелә торган» сүзләре алдына «республика» сүзен өстәргә;

6 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«шул исәптән Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм республика башкарма хакимият органы йөкләмәләренә таянып, автоном коммерциягә карамаган оешманың идарә органы каравына тәкъдим ителә торган мәсьәләләр буенча тавыш бирергә;»;

бишенче абзацта татар текстында «башкарма хакимият органына кертергә» сүзләре алдына «республика» сүзен өстәргә;

8 пунктның тугызынчы абзацында «башкарма хакимият органы тәкъдиме буенча» сүзләре алдына «республика» сүзен өстәргә;

әлеге Тәртипкә кушымтада:

1 бүлектә:

бишенче юлның беренче графасында «Ф.И.Ат.ис.» сүзләрен «Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче юлның беренче графасында «Татарстан Республикасының башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең дүртенче графасы исемендә «Татарстан Республикасының башкарма хакимияте органыннан» сүзләрен «республика башкарма хакимият органын-

нан» сүзләренә алмаштырырга;

4 бүлектә:

исемендә «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

беренче таблицаның беренче графа исемендә «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

икенче таблицаның беренче графа исемендә «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрен автоном коммерциягә карамаган оешманың идарә органнарында тәкъдим итү турындагы шартнамәнең үрнәк формасында:

преамбулада «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга, «вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме» сүзләреннән соң «(булганда)» сүзләрен өстәргә, «фамилиясе, исеме, атасының исеме» сүзләреннән соң «(булганда)» сүзләрен өстәргә;

4 пунктның дүртенче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

12 бүлектә «Ф.И.Ат.ис.» аббревиатурасын «Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт унитар предприятиеләре булмаган юридик затлар (аларның аерылып чыккан җәмгыятьләре) милкендәге капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга һәм (яки) алар тарафыннан күчемсез мөлкәт объектлары сатып алуга бәйле булмаган максатлар өчен әлеге юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет инвестицияләре бирү турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен раслау хакында» 2022 ел, 17 май, 454 нче карары белән расланган Дәүләт учреждениеләре һәм дәүләт унитар предприятиеләре булмаган юридик затлар (аларның аерылып чыккан җәмгыятьләре) милкендәге капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга һәм (яки) алар тарафыннан күчемсез мөлкәт объектлары сатып алуга бәйле булмаган максатлар өчен әлеге юридик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет инвестицияләре бирү турында карарлар кабул итү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимият органы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 18 февраль, 99 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 31 октябрь, 1375 нче
карары редакциясендә)

Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларга
мөлкәти ярдәм күрсәтүгә республика конкурсын үткәрү буенча
конкурс комиссиясе
составы

| | |
|---|---|
| Вәлиева Зилә Рәхимҗан кызы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе, комиссия рәисе (килешү буенча) |
| Бәдриев Илдар Фоат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы |
| Вәлиева Әлфия Фуат кызы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының Социаль мәсьәләләр, хәйрия эшчәнлеге һәм коммерциягә карамаган секторны үстерү комиссиясе рәисе (килешү буенча) |
| Гафиятуллин Мөнир Минхәйдәр улы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Камалетдинов Тимур Ренат улы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының Яшьләр эшләре, ихтыярилыкны үстерү һәм патриотик тәрбия бирү комиссиясе рәисе (килешү буенча) |
| Коновалова Светлана Александровна | «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы аппараты» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Мөбарәкшин Гадел Рәфикъ улы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары |

| | |
|---|---|
| Мөхәммәдьярова Зөлфия Ильяс кызы | Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының икътисад һәм социаль өлкә тармакларын үстерү бүлеге башлыгы |
| Чанышева Юлия Николаевна | Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенең коммерциягә карамаган оешмалар эшләре бүлеге баш белгеч-эксперты (килешү буенча) |
| Шакиров Илнур Ирек улы | Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе урынбасары – Гражданлык җәмгыяте институтлары белән үзара хезмәттәшлек итү идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Шкаликова Лариса Александровна | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт мөлкәтен файдалану бүлеге башлыгы. |

---